

Казан Татарстан китап нәшрияты 1991



ИСӘНМЕСЕЗ-САУМЫСЫЗ

Исәнмесез-саумысыз...
Нигә кәҗә саумыйсыз?
Әтәчегез күкәй салган,
Нигә чыгып алмыйсыз?





ХӘЙЛӘКӘР

Җырларга да мин оста,
Биергә дә мин оста.
Әти-әни эшкә кушса,
Мин авыру, мин хаста.

МИНДӘ ГАЙРӘТ...

Миндә гайрәт,
миндә көч,
Миннән курка үрмәкүч.

ЕЛАК ӘТИ

Әти биштә, мин унбиштә,
Йөрим заводка эшкә.
Әти елый, мин тирбәтәм
Чуман хәтле бишектә.



ӘТӘЧ БЕЛӘН ТАВЫК

Әтәч менгән читәнгә,
«Кикирикүк» итәргә,
Әтәчкә дә хәбәр килгән
Армиягә китәргә.
Әтәч әйтә: «Бармыйм»,— ди,
Тавык әйтә: «Калмыйм,— ди,—
Син армиягә китсәң,
Бер күкәй дә салмыйм»,— ди.
Әтәч армиягә китте,
Чабатага утырып.
Тавык мескен карап калды,
Ике күзен тутырып.





ГАРМУНЧЫ ТАВЫК

Иртән торып тышка
чыксам,
Кырмыска утын кисә.
Кара сарык биеп йөри,
Сыер чәбәкәй итә.

Ак этәч курай тарта,
Тавык гармун уйната.
Шул моңнарга чыдый
алмый
Ата каз елап ята.



КӘҖӘ-МӘКӘРҖӘ

Кәҗә керә бакчага,
Кәбестәне ашарга.
Таяк тотып чыксалар,
Хәзер тора качарга.


Кәҗә, кәҗә-мәкәрҗә,
Кермә минем бакчага.
Кысылырсың киртәгә,
Таяк төшәр җилкәңә.

Кәҗә, кермә бакчама
Яшел суган ашарга,
Яшел суган кикертер,
Читән аша сикертер.

ЙӨКЧЕ КАРГА

Йөгереп чыксам урамга,
Кайтып килә бер карга,
Агыйделдән су төягән
Бастырыклап бер арба.

Агыйделнең аръягында
Чатыр-чотыр ут яна.
Песи китте сүндерергә
Салам төяп бер чана.



БАКА КУНАК ЧАКЫРГАН...

Бака, бака-бакырган,
Бака кунак чакырган.
Кунаклары килмәгәч,
Тышка чыгып акырган.

Бакалар кунакка бара
Чабатага төялеп.
Ике карга карап тора
Себеркегә сөялеп.



ШАПШАК САРЫКЛАР

Ике сарык юлга чыккан
Кулларында чумадан.
Иреннәрен буяганнар,
Ә битләрен юмаган.

УҢГАН ПЕСИ


Безнең песи бигрәк уңган,
Тәпәнгә су тутыра.
Бозавыбыз мич башында
Оек бәйләп утыра.





АУЧЫ КУЯННАР

Иртән торып тышка чыксам,
Сыерлар кар көриләр.
Ике куян, мылтык тотып,
Бүре атып йөриләр.






БОЗ ЯЛАУЧЫ ТАВЫК

Йорт кошларын ашатырга
Иртүк чыгам сарайга.
Тавыкларга тоз ялатам,
Печән салам казларга.





АЯГЫМДА КЫЗЫЛ ЯУЛЫК...

Аягымда кызык яулык,
Башларымда чабата,
Җәйнең эссе көннәрендә
Аягым карга бата.



ИКЕ БАЛЫК...

Суда йөзеп бара идек
Чабатага төялеп.
Ике балык карап калды
Камышларга сөялеп.



ТӘРТИПСЕЗ ЧЕБИЛӘР

Ике чеби алып киткән
Безнең чишмә улагын.
Берсен әтәч тотып алып
Борган, диләр, колагын.

ЭЧТӘЛЕК

Исәнмесез-саумысыз 3
Хәйләкәр 4
Миндә гайрәт . . . 4
Елак әти 5
Әтәч белән тавык . 6
Кәҗә-мәкәрҗә . . 7
Гармунчы тавык . 7
Йөкче карга . . . 8









Бака кунак чакырган 9
Шапшак сарыклар . 10
Уңган песи . . . 10
Аучы куяннар . . 11
Аягымда кызыл яулык 12
Боз ялаучы тавык . 12
Ике балык 13
Тәртипсез чебиләр . 14



10 тиен.



МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ ҺӘМ КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

С УТРА ДО ВЕЧЕРА

Частушки

(на татарском языке)

Рәссамы **Шамил Насыйров**
Төзүчесе **Рәшит Ягъфәров**

ИБ № 5722

Редакторы *М. Фәйзуллина.* Художество редакторы *Ф. Хәсьянова.* Техник редакторы *А. Газизҗанова.* Корректоры *З. Хәсәнова.*
Җыярга тапшырылды 29.06.90. Басарга кул куелды 18.02.91. Форматы 70×90 1/16. Офсет кәгазе № 1. Гарнитурасы «Балтика». Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 4,68. Шартлы буяу-оттиск 4,68. Нәшер-хисап табагы 0,99. Тиражы 50 000 экз. Заказ Д-346. Бәясе 10 тиен.
Татарстан китап нәшрияты. 420111, Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420111, Казань, ул. Баумана, 19. КПССның Татарстан республика комитеты нәшрияты типографиясе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

ББК 84(2Р-Тат)-5

Т $\frac{4801000000 - 057}{М\ 132\ (03) - 91}$ 193 — 90

ISBN 5—298—00492

© Рәшит Ягъфәров, төзү, 1991
© Шамил Насыйров рәсемнәре, 1991